Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай
авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 2**

Троицкий Урай авылы 2020 елның 04 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай
авыл җирлеге Советының
20 14елның 06 октябрендагы
"Җир салымы турында" 12номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге "Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий урай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Советының 2015елның 25 маендагы 12 номерлы, 2017елның 22 августындагы 13 номерлы, 2017 елның 17 ноябрендагы 16 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 10 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып

алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авылы Кама буе ур. 9-йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай авыл җирлеге
Башлыгы Сафин Р.Х.